**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлегенең Мордва Кармалка торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 24 ноябре № 4

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлегенең Мордва Кармалка торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлегенең Мордва Кармалка торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлегенең Мордва Кармалка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 85 яшьтән өлкәнрәк затлардан, МХОда катнашучылар гаиләләреннән тыш, шулай ук 1 һәм 2 төркем инвалидлар өчен билгеләнгән сумманың 50% күләмендә ташламалар белән, 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Мордва Кармалка авылы ФАПына керү юлларына вак таш җәю, Мордва Кармалка авылы ФАПына якын территориядә ачык типтагы яңгыр канализациясе урнаштыру);
2) традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар тоту, төзекләндерү (Мордва Кармалка авылында зират коймасын урнаштыру);
3) су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Мордва Камалка авылында сууткәргеч өзеклекләрен бетерү).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мордва Кармалка авылы, Геодезия урамы, 38а, 2 бина (административ бина), Нагорная ур., 33 йорт (мәдәният йорты бинасы), Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
«Кармалка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы О.В.Кириллова